РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423950, п.г.т. Уруссу, ул. Пушкина, д.38
тел.: (85593) 2-42-05, факс: (85593) 2-80-13

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

423950, Урыссу ш.т.б., Пушкин урамы, 38
тел.: (85593) 2-42-05, факс: (85593) 2-80-13

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«16 »___12___2022 г. №1081

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
территориясендә торак хезмәтләре
күрсәткән өчен түләү күләмен
раслау турында

Россия Федерациясе Торак кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне карап тоту кагыйдәләрен һәм күпфатирлы йортта гомуми мөлкәт белән идарә итү, карап тоту һәм ремонтлау эшләре тиешле дәрәҗәдә башкарылмаган һәм билгеләнгән вакыттан артып киткән очракта торак урынны карап тоту өчен түләү күләмен үзгәртү кагыйдәләрен раслау турында» 13.08.2006 ел, № 491 карары, Россия Төзелеш министрлыгының "Күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында карар кабул итмәгән торак урын милекчеләре өчен торак бинаны карап тотуга түләү күләмен билгеләү буенча методик рекомендацияләрне раслау турында, торак урынны карап тоту өчен түләү күләмен билгеләү, шулай ук мондый түләү күләмен үзгәртүнең чик индексларын билгеләү тәртибен билгеләү турында" 06.04.2018 № 213/пр боерыгы белән, Татарстан Республикасының 28.07.2004 № 45-ТРЗ «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауга кертемнең минималь күләмен билгеләү турында" 29.06.2013 № 450 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына үзгәреш кертү хакында» 2019 елның 3.12.2019 № 1097 карары, Татарстан Республикасы Ютазы районы Советының 28.04.2020 № 18 карары белән кабул ителгән "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы" муниципаль берәмлеге Уставы, Татарстан Республикасы Ютазы район Советының 12.01.2006 № 1 карары белән расланган Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты турында Нигезләмә нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. 2023 елның 1 гыйнварыннан түбәндәгеләрне билгеләргә:

- социаль наем шартнамәләре һәм муниципаль торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннар яллаучылары өчен 2023 елга торак урыннан файдаланган өчен түләү күләмен (наем өчен түләүне) №1 кушымта нигезендә.

- социаль наем шартнамәләре, муниципаль торак фондының торак урыннарын яллаучылар өчен торак урынын карап тоту һәм ремонтлау өчен түләү күләме, күпфатирлы торак йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында карар кабул итмәгән торак урын милекчеләре өчен һәм 2023 елга торак бинаны карап тоту һәм ремонтлау өчен гомуми җыелышта карар кабул итмәгән күпфатирлы торак йорттагы биналарның милекчеләре өчен торак урынын карап тоту һәм ремонтлау өчен түләү күләмен 2 нче кушымта нигезендә.

2. Үз көчен югалткан дип танырга:

«Торак хезмәтләре күрсәткән өчен түләү күләмен раслау турында» Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 29 декабрендәге 1024 номерлы карарын;

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының «Муниципаль торак фондының социаль наем шартнамәләре, торак урыннарын наем шартнамәләре, торак урыннарын яллаучылар өчен , күпфатирлы торак йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында карар кабул итмәүче, гомуми җыелышта 2022 елга торак бинаны карап тоту һәм ремонтлау өчен түләү күләмен билгеләү турында карар кабул итмәүче торак биналар милекчеләре өчен торак урынынннан файдаланган өчен түләү күләмен һәм торак урынын карап тоту һәм ремонтлау өчен түләү күләмен раслау турында» 22.12.2021 № 1080 карарын.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының «Рәсми Татарстан» Бердәм Порталы составында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе С. П. Самонина

Магамедова А. М.
2-42-06

Кушымта №1
Ютазы муниципаль районы
Башкарма комитетының
_____________ 2022 ел № _____
карарына

**2023 елга муниципаль торак фондының социаль наем шартнамәләре һәм торак урыннарын наем шартнамәләре буенча торак урынын яллаучылар өчен торак урыныннан файдаланган өчен түләү күләме (наем өчен түләү)**

| **Түләү исеме** | **Үлчәү берәмлеге** | **Түләү күләме** |
|---|---|---|
| Социаль наем шартнамәләре һәм муниципаль торак фондының торак урыннарын наем шартнамәләре буенча торак урыны наемы өчен түләү | сум/кв.м. | 7,58 |

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Башкарма комитетының
_____________ 2022 ел № _____
карарына

**Социаль наем шартнамәләре, муниципаль торак фондының торак урыннарын яллаучылар өчен торак урынын карап тоту һәм ремонтлау өчен түләү күләме, күпфатирлы торак йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында карар кабул итмәгән торак урын милекчеләре өчен һәм 2023 елга гомуми җыелышта торак урынын карап тоту һәм ремонтлау өчен күпфатирлы торак йорттагы түләүне билгеләмәгән торак биналар милекчеләре өчен түләү күләме**

| **Хезмәтнең исеме** | **Үлчәү берәмлеге** | **2023 елга тариф (.2023 елның 1 гыйнварыннан 2023 елның 31 декабренә кадәр)** |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| Торак фонды белән идарә итү | сум/м2 | 1,69 |
| Йорт яны территориясен җыештыру | сум/м2 | 2,03 |
| Торак бинаны ремонтлау һәм территорияне төзекләндерү | сум/м2 | 3,89 |
| Йорт эчендәге инженерлык челтәрләрен ремонтлау һәм карап тоту: | сум/м2 | |
| суүткәргеч-канализация челтәрләре | | 2,49 |
| газ белән тәэмин итүнең фасад һәм йорт эче челтәрләре | | 0,38 |
| электр белән тәэмин итү челтәрләре | | 1,40 |
| Капиталь ремонт | сум/м2 | 6,48 |